**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Яңа Аксубай җирле үзидарәсенең башкарма комитеты**

**КАРАРЫ**

**2019 елнын 16 декабрь № 16**

“2016-2020 нче елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсендә мәдәниятне үстерү муниципаль максатчан программа” турындагы 2015 нче елның 9 нчы ноябрендәге 19 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында”

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”131-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасының 1998нче елның 3 нче июлендэ кабул ителгән №1705 номерлы ”Мәдәният турында” законы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсенең Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсенең башкарма комитеты **КАРАР ИТӘ**:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсенең башкарма комитетының 2015нче елның 9 нчы ноябрендәге 19 нчы номерлы “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсендә 2016-2020 елларга мәдәният үстерү муниципаль максатчан программа” дигән карарына кушымтада биреләчәк редакциядә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
3. Карарныә үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсенең башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары Питулова И.Н.кызына йөкләргә.

Яңа Аксубай җирле үзидарәсенең
башкарма комитеты җитәкчесе: М.М.Сулейманкин

**Расланган:**
**Яңа Аксубай җирле үзидарәсенең**
**башкарма комитеты җитәкчесе**
**карары белән**
**№ 16 от 16.12.2019 ел**

# “2016-2020 нче елларда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсендә мәдәниятне үстерү”
# Озын сроклы муниципаль максатчан программасы

Яңа Аксубай авылы

**Программаның паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2016-2024 нче елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсендә мәдәниятне үстерү муниципаль максатчан программа |
| Программанын төп нигезләре | Программа РФ, ТР Конституцияләре , федераль һәм ТР законнары, муниципаль берәмлек Уставы, норматив хокукый актлар нигезендә төзелде |
| Муниципаль заказчы- Программаның координаторы | Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсенең башкарма комитеты |
| Программаның төп төзүчеләре | Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсенең башкарма комитеты |
| Программаның максатлары | Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсендә яшәүчеләрнең мәдәният,сәнгать һәм кинемотография өлкәсенә каранан ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңаларын формалаштыру, җирлектә яшәүчеләр һәм кунаклар өчен мәдәният, сәнгать һәм кинемотография учреждениеләренең кызыксындыручанлыгын арттыру, Яңа Аксубай җирлеге территориясендә экстремизм һәм терроризмга каршы тору, аларның җирлектә булмавынпрофилактикалау нигезендә җирлектә яшәүчеләрнең законлы хокук һәм карашларын, куркынычсызлык дәрәҗәсен һәм тынычлыгын арттыру |
| Программаның бурычлары | 1. Милли музыкаль традицияләрне саклау һәм үстерү, хәзерге заман музыка сәнгатен үстерү;<br>2. Милләтара һәм конфессияләр арасындагы дуслыкны ныгыту, социаль, этник, конфессиональ нигездәге низагларны профилактикалау һәм булдырмау;<br>халыкта террористик һәм экстремистик идиологиягә карата тискәре атмосфера тудыруга юнәлтелгән фикер формалаштыру. |
| Тормышка ашыру вакыты | 2016-2024 нчы еллар |
| Ярдәмче программалар | - “2016-2024 нче елларга башкару сәнгатен һәм клуб концерт оешмаларын үстерү»<br>- “2016-2024 нче елларга терроризм һәм экстремизмны профилактикалау» |
| Программаны финанслау күләме | 2016-2024 нче елларда Программаны финанслау күләме 9475,3 мең. сум, шул исәптән:<br>2016 год –765 мең сум<br>2017 год – 776,5 мең сум<br>2018 год – 785,0 мең сум<br>2019 год- 799,8 мең сум<br>2020 год- 1261,0 мең сум<br>2021 год-1265,0 мең сум<br>2022 год-1270,0 мең сум<br>2023 год-1275,0 мең сум<br>2024 год- 1280,0 мең сум |

| | |
|---|---|
| | Искәрмә: Программаны финанслау күләме прогноз характерын йөртә һәм билгеле бер елга билгеле бер дәрәҗәдәге бюджетны формалаштырганда ел саен төзәтмәләр кертү, шулай ук чараларны софинанслау өчен федераль һәм республика бюджетыннан акчалар бүлеп бирүне таләп итә |
| Программаны ә максат һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет эффективлыгы күрсәткечләре | Программа чараларын тормышка ашыру 2020 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>төрле дәрәҗәдәге конкурс, фестивальләрдә катнашучыларның санын арттыру:<br>массакүләм һәм мәдәни-массалы чараларда катнашучылар санын арттыру;<br>үзешчән сәнгать формированиеләрен һәм аларда катнашучылар санын арттыру;<br>җирлектә яшәүче халыкларның этномәдәни үзенчәлеген саклауга юнәлдерелгән мәдәни акция һәм программаларны 5 чарага кадәр арттыру;<br>дәүләт органнары, мәдәни-агарту учреждениеләре, милли-мәдәни берләшмәләр, шулау ук аерым гражданнар белән уртак проектлар күләмен 2 проектка кадәр арттыру;<br>җирлектә татар милли бәйрәме Сабантуйны оештыру күләме-1;<br>террорчылык һәм экстремистлык күренешләренең барлык фактларына карата түземсезлек формалаштыруны камилләштерә..<br><br>Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирлеге территориясендә толерантлык, башка милләтләргә карата хөрмәтне пропагандалау һәм тарату өчен бердәм мәгълумати җирлек формалаштыру;<br><br>Яшьләр арасында милләтара толерантлык һәм дустанә атмосфераны ныгыту. |
| Программа үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсе Советы;<br>Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсе башкарма комитеты; |

## Программаны тормышка ашыру сферасының гомуми характеристикалары, шул исәптән ул чишәргә юнәлдерелгән проблемалар

Бүгенге көндә Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирлегендә 2 муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениясе эшли. Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирлегенең мәдәни объектлар челтәре үз эченә 2 китапханә, мәдәни-күңел ачу тибындагы 2 учреждениены ала. Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирлегендә мәдәният һәм сәнгать үсешенә ярдәм максатларыннан 2014 нче елда җирлек бюджетыннан 706,7 мең сум бүлеп бирелгән. Бу өлкәдә 6 кеше хезмәт куя. Акчаларның күп өлеше өлкәгә караган

объектларны төзү, реконструкцияләү, материаль-техник базаларын ныгыту, комплексы мәгълуматлаштыру һәм мәдәният учреждениеләрен яңартуга тотыла.

Социологик тикшеренүләр нәтиҗәсенә караганда эшләп килүче мәдәни учреждениеләр челтәре халык ихтыяҗларын тулы күләмдә канәгатьләндерми. Халык фикеренчә җитешсезлекләр түбәндәгеләр белән бәйле:

Мәдәни объектларның тигез урнашмавы, эшләп килүче учреждениеләрдә “керү ирегe” чагыштырмача югары булу;

Мәдәни учреждениеләр күрсәтә торган хезмәтләр күләме һәм төрле гражданнар өстенлек бирә торган һәм көткән ихтыяҗларга тулы дәрәҗәдә туры килмәве;

Мәдәният учреждениеләренең ял һәм иҗади эшчәнлек,белем бирү һәм үзлегеннән белем алу, чаралар үткәрү, берләшмәләр эшен оештыру өчен заманча югары технологик җиһазлар белән тээмин ителмәве, шулай ук төрле катлам вәкилләре өчен мәдәният учреждениеләренә керү мөмкинлеге булдыру, шул исәптән мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен һәм башка чикләүләр буенча;

төрле жанрдагы(музыкаль, театраль) сәнгати фестивальләрне үткәрү, концерт-филормоник һәм күргәзмә эшчәнлеге, концерт һәм башка сәнгать коллективлары чыгышы өчен база буларак куллану өчен югары дәрәҗәдәге заманча зур комплексларның аз булуы.

**Мәдәният өлкәсендәге проблемаларны чишү механизмы**

| Проблеманың эчтәлеге | Чишү механизмы |
|---|---|
| Мәдәни-ял чаралары гражданнарның барлык ихтыяҗларын да канәгатьләндерми. | Мәдәни-ял эшчәнлеге сферасына яңа форма һәм методлар кертү |
| мәдәният учреждениеләренең материаль-техник базалары тулы булмау | материаль-техник базаларны ныгыту, өлкәне мәгълүматлаштыру, җиһазларны яңарту, дәүләтнеке булмаган структураларны, бюджеттан тыш акчаларны җәлеп итү |
| Мәдәният учреждениеләренә мөмкинлекләре чикле кешеләр, инвалидлар өчен керү мөмкинлеге булмау | мәдәният учреждениеләрен махсус техника белән тулыландыру, мәдәният учреждениеләренә мөмкинлекләре чикле кешеләр, инвалидлар өчен керү мөмкинлеге булдыру, читтән торып хезмәт күрсәтүне үстерү |
| Инновацион мәдәни проектлар булдыру һәм гамәлгә ашыру кирәклеге | Инновацион проектларны, иҗади остаханәләрне грантлар белән ярдәм итү |

## Программа максатларына ирешүгә киртә булырлык чаралар белән идарә итү

Программа максатларына ирешүгә киртә булырлык чараларны анализлау һәм алар белән идарә итүне муниципаль заказчы - Программа координаторы - Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай җирле үзидарәсе башкарма комитеты.

Иң җитди рискларга ярдәмче программаларны гамәлгә ашыруның финанс һәм административ рискларын кертергә мөмкин. Финанс рискы программа буенча кабул ителгән финанс йөкләмәләрен тулысынча үтәмәүдән гыйбарәт. Финанс рискын чикләү ысулы булып программа чараларының финанс күрсәткечләренә һәм күрсәткечләргә ирешелгән нәтиҗәләргә

карап ел саен төзәтмәләр кертү тора. Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге бюджетыннан Программа чараларын финансламау куркынычын минимальләштерү мәдәният, социаль партнерлык өлкәсендә инновацион проектларның инвестицион җәлеп итүчәнлеге механизмнарын формалаштыру юлы белән тормышка ашырыла. Административ риск ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын үтәмәүгә китерергә мөмкин булган нәтиҗәсез идарә итү программасы белән бәйле. Административ рискны чикләү ысуллары булып түбәндәгеләр тора:

Программа чараларының үтәлешен һәм Программаны тормышка ашыруның механизмын камилләштерүне контрольгә алу;

Программаны тормышка ашыруның еллык планнарын формалаштыру;

Программа күрсәткечләренең(индикаторларының)үтәлешен даими күзәтү;

Программаны тормышка ашыру барышы турында халыкны таныштыру һәм аны бастырып чыгару;

Гамәлгә ашыруга куркыныч тудырган чаралар белән муниципаль заказчы – Программа координаторы Программаны тормышка ашыруны мониторинглау һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү нигезендә идарә итә.

**Программаның төп максатлары, бурычлары, нәтиҗәләре**

**һәм аны гамәлгә ашыру вакыты**

Программаның максаты - 2014-2020 елларга "Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү" республика программасы белән билгеләнгән Татарстан Республикасы Дәүләт мәдәни сәясәте приоритетларына нигезләнгән.

Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеше максатларында мәдәният һәм сәнгать өлкәсен тотрыклы үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру белән беррәттән, әлеге программаның стратегик максаты булып Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегендә яшәүчеләрнең мәдәният, сәнгать өлкәсендә агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру, мәдәният, сәнгать учреждениеләренең җәлеп итүчәнлеген арттыру тора. Әлеге максатка ирешү өчен системалы характерда булган кайбер мәсьәләләрне, шул исәптән, хәл итәргә кирәк:

милли музыкаль традицияләрне саклау һәм үстерү, заманча музыка сәнгатен үстерү;

Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегендә халык сәнгатен саклау, өйрәнү һәм үстерү;

Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектларының сакланышын һәм нәтиҗәле кулланылышын тәэмин итү;

төбәкара һәм милләтара мәдәни хезмәттәшлекне үстерү өчен шартлар тудыру

Программа үзенчәлекле бурычлары тиешле ярдәмче программаларда чагылдырылган программа чараларын гамәлгә ашыруның муниципаль дәрәҗәсен күздә тота.

"2016-2020 елларга концерт оешмаларын һәм башкарма сәнгатьне үстерү" подпрограммасы милли музыкаль традицияләрне саклау һәм үстерү, заманча музыка сәнгатен үстерү максатын куя. Җирлекнең муниципаль концерт оешмалары челтәренең бүгенге торышын, 2020 елга кадәр

концерт учреждениеләренең үсеш перспективаларын чагылдыра.

Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегендә терроризм һәм экстремизмны профилактикалау " ярдәмче программасы терроризм һәм экстремистлык күренешләренең барлык фактларына карата түзеп тормауны, Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлеге территориясендә толерантлык, башка культураларга карата хөрмәт һәм ихтирам идеяләрен пропагандалау һәм тарату өчен бердәм мәгълүмати киңлек булдыруны камилләштерә;

Программаны гамәлгә ашыру срогы - 2016-2024 еллар.

## Программаны ресурслар белән тәэмин итү нигезләү

Программаны тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелә торган федераль бюджет, Республика, шулай ук Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлеге бюджеты акчаларын куллануны күздә тота**.** Программаны финанслауның гомуми күләме 9475,3 мең. сум, шул исәптән:
2016 год –765 мең сум
2017 год – 776,5 мең сум
2018 год – 785,0 мең сум
2019 год- 799,8 мең сум
2020 год- 1261,0 мең сум
2021 год-1265,0 мең сум
2022 год-1270,0 мең сум
2023 год-1275,0 мең сум
2024 год- 1278,0 мең сум

Программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү фаразланган характерга ия һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## Программаны тормышка ашыру механизмы

Программа чараларын тормышка ашыру барышында муниципаль заказчы-координатор төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә, чараларны тормышка ашыру барышын һәм турыдан-туры башкаручыларның акчаларын нәтиҗәле файдалануны контрольдә тота. Программа чараларын тормышка ашыру программа заказчысы тарафыннан Программа чараларын башкаручылар белән төзелә торган муниципаль контрактлар нигезендә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә катгый рәвештә гамәлгә ашырыла.

### Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Мәдәниятнең фундаменталь үзенчәлеге шунда ки, мәдәният эшчәнлегенең мөһим нәтиҗәләре вакыт буенча билгеләнгән социаль эффектта чагылыш таба һәм интеллектуаль потенциалны арттыруда, шәхесләрнең кыйммәтле ориентирларын һәм үз-үзләрен тоту нормаларын үзгәртүдә чагыла.

Программада мәдәни эшчәнлекнең агымдагы нәтиҗәләрен генә тасвирлый торган индикаторлар системасын һәм цифрлы күрсәткечләрне куллану күздә тотыла. Шул ук вакытта конкрет Подпрограммада үзләренең нәтиҗәлелек күрсәткечләре булырга мөмкин. Программаны һәм аның ярдәмче программаларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү Программаның муниципаль заказчы - координаторы тарафыннан гамәлгә ашырыла**.**

Программаны тормышка ашыруның төп социаль-икътисади нәтиҗәсе Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлегендә яшәүче гражданнар тормышында мәдәниятнең социаль

ролен күтәрүдә һәм, димәк, Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлегендә яшәү сыйфатын күтәрүдә, мәдәният өлкәсендә модернизация курсын тормышка ашыру өчен уңай җәмәгать мохите тудыруда чагыла. Бу эффект аерым алганда түбәндәгеләрдә чагылыш табачак:

Аксубай районының Яңа Аксубай авыл җирлегендә яшәүче халыкларның үзенчәлеге белән бергә бөтенлекне саклап калырга ярдәм итә торган мәдәни киңлекнең бердәмлеген ныгытуда;

иҗади эшчәнлек өчен уңай шартлар тудыру, халыкка тәкъдим ителә торган мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге мәдәни байлыкларның һәм мәгълүматларның төрлелеге һәм һәркем куллана алсын өчен уңайлы шартлар тудыру;

мәдәниятне икътисадый үстерү процессларын активлаштыруда һәм тармакка җәлеп ителә торган дәүләтнеке булмаган ресурсларны үстерүдә;

Мәдәниятне үстерү бурычлары әйләнә-тирә мохитне саклау бурычлары белән тыгыз бәйләнгән. Кагыйдә буларак, бу элемтә мәдәни ландшафтларны һәм истәлекле урыннарны саклау өлкәсендә, музей-тыюлыклар эшчәнлегендә чагыла. Истәлекле урыннар һәм саклана торган тарихи-мәдәни территорияләр системасын формалаштыру Экология һәм табигый мирасны саклау проблемаларын хәл итүгә турыдан-туры бәйле. Шулай итеп, Программа әйләнә-тирә мохитне саклау бурычы белән тыгыз элемтәдә мәдәниятне үстерү проблемаларын хәл итә. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге программада каралган максатчан индикаторларның һәм күрсәткечләрнең факттагы ирешү дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

## "2016-2024 елларга клуб концерт оешмалары һәм башкарма сәнгатьне үстерү" ярдәмче программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Муниципаль ярдәмче программаның исеме | 2016-2024 елларга клуб концерт оешмалары һәм башкарма сәнгатьне үстерү |
| Муниципаль ярдәмче программаның максатлары | Аксубай районының Яңа Аксубай авыл җирлеге территориясендә бердәм мәдәни киңлек булдыру һәм саклау;<br><br>- мәдәният учреждениеләренең муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар , мәгариф системасы учреждениеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗади һәм дини оешмалар белән ведомствоара хезмәттәшлеген үстерү;;<br><br>- халыкта гражданлык тәңгәллеген, мораль-әхлакый һәм толерант караш формалаштыру буенча эшчәнлекне оештыру.<br><br>- эш юнәлешләрен һәм рәвешләрен камилләштерү ;<br><br>- мәдәни-ял итү учреждениеләрендә чараларның сыйфатын арттыру |
| Муниципаль ярдәмче программаның бурычлары | Җирлекнең мәдәниятен, сәнгатен үстерү, тарихи-мәдәни мирасын саклау һәм популярлаштыру өчен шартлар тудыру.<br><br>План нигезендә массакүләм һәм бәйрәм мәдәни-массакүләм чаралар үткәрү.<br><br>Мәдәни-ял чараларында катнашучылар санын арттыру.<br><br>Халык арасында гражданлык тәңгәллеген формалаштыруны, иҗади потенциалны ачуны, толерантлык, этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр культурасын тәрбияләүне тәэмин итә |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | торган «мәдәният» өлкәсендә системаны үстерү һәм модернизацияләү | | | | | | | | | |
| Муниципаль ярдәмче программаның муниципаль заказчысы | Татарстан Республикасы Аксубай районының Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма комитеты | | | | | | | | | |
| Муниципаль ярдәмче программаны төзүче | Татарстан Республикасы Аксубай районының Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма комитеты | | | | | | | | | |
| Муниципаль ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты | 2016-2020нчы еллар | | | | | | | | | |
| Муниципаль ярдәмче программаны финанслау чыганаклары, шул исәптән еллап | Финанслау чыганагы булып Аксубай районының Яңа Аксубай авыл җирлеге бюджеты тора | | | | | | | | | |
| | Чыгымнар (меӊ сум). | | | | | | | | | |
| | барлыгы | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| Җирле бюджет акчалары | 94,75,3 | 765,0 | 776,5 | 785,0 | 799,8 | 1261,0 | 1265,0 | 1270,0 | 1275,0 | 1278,0 |
| Тормышка ашырылучы муниципаль ярдәмче программаны планлаштырылган нәтиҗәләре | Төрле дәрәҗәдәге конкурсларда, фестивальләрдә катнашкан катнашучылар санын арттыру;<br>Клуб формированиеләрендә катнашучылар алган дипломнар, премияләр санын арттыру;<br>Массакүләм һәм мәдәни-массакүләм чараларда катнашучылар санын арттыру;<br>Үзешчән сәнгать клубларының формированиеләрен һәм анда катнашучылар санын арттыру; | | | | | | | | | |

## I. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенең Гомуми характеристикасы, шул исәптән ул хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар да

Халыкның рухи тормышын оештыручы факторларның берсе буларак, мәдәниятнең социаль роленең артуы җәмгыять үсешенең заманча этабы булып тора. Шул ук вакытта мәдәният кешелекнең рухи тәҗрибәсе буларак кына түгел, ә һәр кешенең иҗатка сәләтен формалаштыручы, кеше яшәеше нигезләрен, цивилизацияле тормыш рәвешләрен саклап калу сәләтенә нигез салучы үзенчәлекле чынбарлык буларак та тора. Иҗади көчләрне, кешенең сәләтләрен һәм талантларын күрсәтү һәм үстерү өчен кирәкле шартлар булу җәмгыятьнең мәдәни үсешенең мөһим критерие булып тора. Халыкның тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән мәсьәләләрне хәл итү җирле үзидарә органнарының мәдәният өлкәсендәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыру белән билгеләнә һәм әлеге проблемаларны программа-максатчан метод нигезендә хәл итәргә кирәк. Муниципаль программа чараларын тормышка ашыру мәдәният учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга юнәлдерелгән –Бу Аксубай районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең социаль-икътисади үсешенең иң мөһим ресурсларыннан берсе буларак мәдәниятне хәзерге шартларда тануны билгели торган конкрет адымнар.

Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру мәдәни эшчәнлекнең барлык субъектлары катнашында социаль әһәмиятле максатларга ирешергә мөмкинлек бирәчәк, бюджет ресурсларын нәтиҗәле тотуны тәэмин итәчәк һәм түбәндәгеләрне эшләргә ярдәм итәчәк:

1.Җирлекнең мәдәниятен, сәнгатен үстерү, тарихи – мәдәни мирасын саклау һәм популярлаштыру өчен шартлар тудыру.

2.План нигезендә массакүләм һәм мәдәни-массакүләм бәйрәм чаралары үткәрү.

### ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

1. Мәдәни-ял итү юнәлешендәге системаны модернизацияләү.

Әлеге процессны камилләштерү буенча чаралар системасы тарафыннан түбәндәгеләр күздә

тотыла:

- клуб, китапханә системасында халык белән эшләүнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү;;
- инновацион формалар һәм методлар үсеше;
- районның муниципаль берәмлекләре белән хезмәттәшлекне тәэмин итү;
- мәдәни-ял чараларын популярлаштыру.

Мәдәни-ял итү учреждениеләрендә мәгълүмати, фәнни-теоретик һәм методик тәэмин ителеш.

- «мәдәният» өлкәсендә программалар һәм методикалар комплексын эшләү»;
- балалар, яшүсмерләр һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү формаларын, метод һәм чараларын булдыру;
- җирлекнең социаль-икътисади үсешендә мәдәният учреждениеләрен тагын да киңрәк файдалану өчен шартлар тудыру;
- халыкның иҗади потенциалын үстерүгә булышлык күрсәтү.

**Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегендә терроризм һәм экстремизмны профилактикалау ярдәмче программасыных паспорты**

| | |
|---|---|
| Муниципаль ярдәмче программаның исеме | **Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегендә терроризм һәм экстремизмны профилактикалау** (алга таба – ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаны төзүчеләр | Татарстан Республикасы Аксубай районының Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Ярдәмче программаның максатлары | Экстремизм һәм терроризмга каршы тору, аларның чагылышларын кисәтү нигезендә Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегендә яшәүче гражданнарның тормыш-көнкүреш шартларын, аларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсен күтәрү |
| Ярдәмче программаның бурычлары | Милләтара һәм конфессияара килешүне ныгыту, социаль, этник һәм конфессиональ җирлектә конфликтларны кисәтү һәм булдырмау;<br>Халыкта террорчылык һәм экстремистлык идеологиясе күренешләренә карата түземсезлек атмосферасын булдыруга юнәлтелгән иҗтимагый фикер формалаштыру |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты һәм этпалары | 2016-2024 еллар |
| Ярдәмче программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге бюджеты акчалары хисабыннан ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 20,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән<br>2016 год –3 мең сум<br>2017 год –3,05 мең сум<br>2018 год – 3,1 мең сум<br>2019 год- 3,15 мең сум<br>2020 год- 1,0 мең сум<br>2021год-1,0 мең сум |

| | |
|---|---|
| | 2022год-1,0 мең сум<br>2023год-1,0 мең сум<br>2024год-1,0 мең сум<br><br>Искәрмә: ярдәмче программаны финанслау күләме фаразланган характерга ия һәм тиешле елга тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук чараларны финанслауга район һәм республика бюджетыннан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре | Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру терроризм һәм экстремистлык күренешләренең барлык фактларына карата түземсезлек формалаштыра;<br><br>Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге территориясендә толерантлык, башка мәдәниятләргә карата хөрмәт һәм ихтирам идеяләрен пропагандалау һәм тарату өчен бердәм мәгълүмати киңлек булдыру;<br><br>Яшьләр арасында этникара татулык һәм толерантлык атмосферасын ныгыту. |
| Ярдәмче программаның үтәлешен тикшерүне оештыру | Ярдәмче программаны тормышка ашыруны Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы контрольдә тота. |

## II. I. Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманың характеристикасы

Ярдәмче программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, шәхес, җәмгыять һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге федераль законнар, 2009 елның 5 октябрендәге Россия Федерациясендә терроризмга каршы тору концепциясе, 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясе, шулай ук милләтара, динара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә һәм яшьләрне патриотик тәрбияләүгә юнәлтелгән башка стратегияләр, концепцияләр тәшкил итә.

Хәзерге вакытта Аксубай районының Яңа Аксубай авыл җирлегендә бер дини оешма теркәлгән, шул исәптән мөселман-1; православие-юк; теркәлмәгән дини оешмалар: мөселман - 3; православие-1.

Иҗтимагый-сәяси, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы төрле социаль төркем, милләт һәм дин вәкилләре арасында тотрыклылык, дустанә, конструктив хезмәттәшлек белән характерлана. Соңгы елларда дин тотучылар күләме, чиркәү һәм мәчетләр саны артты.

Шуның белән бергә, ярдәмче программаны әзерләү һәм аны алга таба гамәлгә ашыру зарурлыгы Татарстан Республикасында террорчылык һәм экстремизмга каршы көрәш өлкәсендәге бүгенге вәзгыять киеренке булып калу белән бәйле.

Хәзерге вакытта террорчылык һәм экстремизмга каршы көрәш практикасы дәүләт хакимияте, җирле үзидарә, иҗтимагый хәрәкәт һәм барлык гражданнарның тырышлыгын берләштерүне таләп итә.

Чараларны үтәү Аксубай муниципаль районының Яңа Аксубай авыл җирлеге алдында торган иң кискен проблемаларны, террорчылыкка каршы тору дәрәҗәсен күтәрүнең уңай

тенденцияләрен булдыру ягыннан хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк, нәтиҗәдә гомуми куркынычсызлыкны ныгытуга турыдан-туры йогынты ясаячак.

### III. “Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегендә 2016-2024 елларда террорчылык һәм экстремизмны кисәтү буенча эшне оештыру” ярдәмче программасының чаралары

| № п/п | Чаралар исемлеге | Башкару вакыты | Башкаручы<br><br>(килешү буенча) |
|---|---|---|---|
| 1 | Авыл яшьләрен эш белән тәэмин итү, буш вакытларын үткәрү һәм һөнәри белем алу мөмкинлекләрен киңәйтү; авыл яшьләренең иҗтимагый хәрәкәтен үстерү буенча өстәмә чаралар күрергә | 2016-2024 еллар. | Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең башкарма комитеты, Аксубай муниципаль районы башкарма комитетының "Мәдәният бүлеге" МКУ, яшьләр эше һәм спорт бүлеге |
| 2 | Яшүсмерләр арасында экстремизмны профилактикалау өлкәсендәге программалар һәм проектларның республика конкурсында катнашу һәм аларны балалар һәм яшьләр оешмалары эшчәнлегендә гамәлгә ашыру. | 2016-2024 еллар | Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге,<br><br>Аксубай муниципаль районының “Мәдәният бүлеге” МКУ, “Мәгариф бүлеге” |
| 3 | Җирлек дини берләшмәләрендә дин тотучыларга террорчылык һәм экстремизмны бәяләүгә юнәлдерелгән вәгазьләр һәм җомга намазлары вакытында даими рәвештә вәгазьләр сөйләүне оештыру | 2016-2024 еллар. | Җирлек башлыгы |
| 4 | Басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары материалларына, укыту-методик әдәбият һәм башка басмаларга экспертиза үткәрүне оештырырга. | 2016-2024 еллар | Россия МВДның Аксубай районы буенча бүлеге (килешү буенча) |
| 5 | Потенциаль куркыныч объектларны паспортлаштыру. | 2016-2024 еллар | Россия МВДның Аксубай районы буенча бүлеге (килешү буенча), Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең башкарма комитеты |
| 6 | Җәмгыятьнең әхлакый сәламәтлеген ныгыту, милләтара һәм динара мөнәсәбәтләр, кешеләр күп була торган объектларның, халыкның тормыш-көнкүрешен тәэмин итүче объектларның террорчылыкка каршы якланышы мәсьәләләре буенча | 2016-2024 еллар | Аксубай муниципаль районының “Мәдәният бүлеге” МКУ, “Мәгариф бүлеге, Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең башкарма комитеты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | «түгәрәк өстәлләр» уздыру. | | |
| 7 | Формаль булмаган берләшмәләрне ачыклау буенча рейдлар. | 2016-2024 еллар | Россия МВДның Аксубай районы буенча бүлеге (килешү буенча) |
| 8 | Теркәлмәгән дини һәм милли берләшмәләрне ачыклау өчен дини конфессия һәм милли диаспора вәкилләре белән әңгәмәләр үткәрү | 2016-2024 еллар | Россиянең Татарстан Республикасы буенча Аксубай районындагы УФМС бүлеге (килешү буенча), |
| 9 | Кешеләр күп була торган биналарда гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу очраклары буенча өйрәнүләр үткәрү | 2016-2024 еллар | Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең башкарма комитеты<br><br>Россия МВДның Аксубай районы буенча бүлеге (килешү буенча) ФГКУ «ТР буенча 102 ЯЧ ФПС” ФДКУ (килешү буенча) |
| 10 | Системалы рәвештә барлык типтагы белем бирү учреждениеләрендә экстремизмның теләсә нинди, бигрәк тә милләтара һәм диниара дошманлык уятучы иҗтимагый куркыныч тудыруын аңлату буенча сыйныф сәгатьләрен уздыру | 2016-2024гг | Аксубай муниципаль районының “Мәгариф бүлеге, Аксубаевского муниципаль районының дини конфессия вәкилләре (килешү буенча), Россия МВДның Аксубай районы буенча бүлеге (килешү буенча) |
| 11 | Подпрограмма чараларын мәгълүмати яктыртуны оештыру | Ел дәвамында | “Авыл таңнары” газетасы редакциясе (килешү буенча), стенды в клубах<br>Яңа Аксубай җирлегендәге мәдәният йортларындагы стендлар |